# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2025 елның 21 ноябре № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьясы белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 21 ноябрендә сәгать 13.00 «2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хәрби операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз)сум күләмендә җыярга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) Дружба торак пунктыны чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, традицион күмү урыннарына кадәр юлларны вак таш белән каплау (махсус техника, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдерлау);

2) Дружба торак пунктында урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы карап тору (шартнамә буенча лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 38 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 23 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
позиция өчен гражданнар җыенында катнашучы 23 кеше тавыш бирде; каршы позиция өчен _0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны таныргa: «2026 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500(биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хэрбџ операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, ризамы, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1) Дружба торак пунктыны чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, традицион күмү урыннарына кадәр юлларны вак таш белән каплау (махсус техника, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдерлау);

2) Дружба торак пунктында урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы карап тору (шартнамә буенча лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Ләке авыл җирлегенең информацион стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы ________________ Ю.Г.Антонов.